**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Иске Казиле авыл җирлеге Атабай авылында**
**гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

08 нче декбрь 2019 ел № 1

“Россия Федерациясендә җирле узидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 121-ФЗ номерлы Федераль законнын 25,1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле узидарә турында” 2004 елнын 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 нчы елның 8 нче декабрендә булып узган гражданнар жыены нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде: «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлегенә кергән Атабай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән (көндезге формада белем алучы студентлардан тыш) 2020 елда 3000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны, җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча түбәндә язылган эшләрне хәл итүгә куллану белән килешәсезме:

-Атабай авылында юлларны ремонтлау һәм карап тоту;
-торак пункт территорияләрен төзекләндерү, шул исәптән чүп үләннәрен чабу һәм Яңа ел бизэклэре сатып алу;
- күмү урыннарын тәртиптә тоту һәм ремонтлау, триммер һәм бензин пычкысы сатып алу;
- беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү;
- урам исемнәре һәм йорт номерлары булган күрсәткечләр урнаштыру».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 47 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 35 кеше тавыш бирүдә катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 35 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте**:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге составына керүче Атабай авылы халык җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип санарга.

2. «2020 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлеге территориясе, Атабай авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән (көндезге формада белем алучы студентлардан тыш) 3000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган

акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерүгә җибәрүгә килешәсезме:

-Атабай авылында юлларны ремонтлау һәм карап тоту;

-торак пункт территорияләрен төзекләндерү, шул исәптән чүп үләннәрен чабу һәм Яңа ел бизәкләре сатып алу;

- күмү урыннарын тәртиптә тоту һәм ремонтлау, триммер һәм бензин пычкысы сатып алу;

- беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү;

- урам исемнәре һәм йорт номерлары булган күрсәткечләр урнаштыру».

соравы буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. 2020 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлеге территориясе, Атабай авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән (көндезге формада белем алучы студентлардан тыш) 3000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерергә:

-Атабай авылында юлларны ремонтлау һәм карап тоту;

-торак пункт территорияләрен төзекләндерү, шул исәптән чүп үләннәрен чабу һәм Яңа ел бизәкләре сатып алу;

- күмү урыннарын тәртиптә тоту һәм ремонтлау, триммер һәм бензин пычкысы сатып алу;

- беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү;

- урам исемнәре һәм йорт номерлары булган күрсәткечләр урнаштыру».

4. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

1) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Иске Казиле авылы, Һади Такташ ур., 4;

2) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Каратал авылы, Күпер урамы, 5;

3) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Атабай авылы, Үзәк урамы, 14; шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче ,
Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Иске Казиле авыл җирлеге
башлыгы: И.Х. Сәгдиев